БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_02_» ___10___ 2019 г. № _308_

**Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2019 елның 5 июлендәге 254 нче номерлы карары белән расланган Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатуларны үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында (19 нчы кушымта)**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау хакында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Балтач муниципаль районында күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2019 елның 19 апрелендәге 167 нче номерлы карары һәм Балтач районы прокуратурасының 2009 елның 23 августындагы 02-08-03-19 номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасының Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатуларны үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы административ регламентның 1 нче бүлегендәге 1.2 пунктына (19 нчы кушымта), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

- «Муниципаль хезмәт алучы (алга таба - мөрәҗәгать итүче) Россия Федерациясенең Җир кодексының 39.6 маддәсенең 2 нче һәм 3 нче пунктларында күрсәтелгән физик һәм юридик затлар».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында baltasi.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов